ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37,
423964,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 3 29.11.2021

2022 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендәге Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 8 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, 2019 елның 10 сентябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 11 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 10 декабрендә 14.00 сәгатьтә авыл клубы бинасы янында, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Көрәш-Бүләк авылы, Совет урамы, 9А йорт адресы буенча 2022 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
1. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән,көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-Көрәш-Бүләк торак пунктындагы авылга керә торган юл-урам чөлтәре торышын норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак ком-таш катнашмасы җәю, төзелеш материаллары сатып алу, кайтару, түшәү, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Көрәш-Бүләк торак пунктында авыл клубы территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (грейдер белән узу, кардан чистарту, килешү буенча түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Бәйрәкәтамак авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов